**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Чирмешән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**21 ноябрь 2024 ел** **№ 11**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
составына керүче
Түбән Чегодай торак пунктында
үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Түбән Чегодай торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Чирмешән авыл җирлегенең Түбән Чегодай торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугышчы-интернационалистларның тол хатыннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә яшәүче гражданнардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

**- коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Түбән Чегодай торак пунктындагы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту, дератизация чараларына түләү, корыган агачларны һәм куакларны кисү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Түбән

Чегодай торак пунктындагы гомуми белем бирү учреждениеләренең урам яктыртуларын монтажлау, демонтажлау, ремонтлау, алмаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Түбән Чегодай торак пунктындагы чишмәләр территорияләренең санитария-яклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Түбән Чегодай торак пунктында урамнарны карап тоту, үлән чабу, ботакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар сатып алу, тракторны тоту, аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен материаллар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, арба һәм махсус техника сатып алу, кирәкле запас частьләр сатып алу).

3. Бу карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.С. Хәлиуллин